**ХАЛЫК ЖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**«06» апрель 2024 ел № 2**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Бирәзә авыл җирлегенең Наласа авылында халык җыенынәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлегенең Урта Бирәзә авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Наласа авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Наласа авыл җирлегенең Урта Бирәзә авылында 2024 елның 06 апрелендә "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Наласа авыл җирлегенең Урта Бирәзә авылында халык җыены нәтиҗәләре турында" 2023 елның 17 ноябрендәге 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча узган халык җыены мәсьәләсен яңа редакциядә бәян итү өлешендә халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Урта Бирәзә авылы, Наласа авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 1000 сум тәшкил иткән балачактан инвалидлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- торак пункт территориясен төзекләндерү (балалар спорт мәйданчыгы төзү — 2; универсаль спорт мәйданчыгының нигезен төзү; Урта Бирәзә авылында куакларны санитар кисү һәм чыгару, территорияне чистарту);
- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәсен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (яктырткычлар, лампалар сатып алу һәм урнаштыру).

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

"ӘЙЕ" "КАРШЫ"

Халык җыены беркетмәсе нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 188 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 99 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 99 кеше тавыш бирде; " Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлегендә Урта Бирәзә авылы халык җыенын узган һәм аның нәтиҗәләре дөрес дип таныргa.

2. Халык җыены мәсьәләсен яңа редакциядә бәян итү мәсьәләсе буенча карарны таныргa: «Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Урта Бирәзә авылы, Наласа авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 1000 сум тәшкил иткән балачактан инвалидлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- торак пункт территориясен төзекләндерү (балалар спорт мәйданчыгы төзү — 2; универсаль спорт мәйданчыгының нигезен төзү; Урта Бирәзә авылында куакларны санитар кисү һәм чыгару, территорияне чистарту);

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәсен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (яктырткычлар, лампалар сатып алу һәм урнаштыру).

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда кабул ителгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә, карар кабул ителгән дип таныргa».

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Наласа авылы, Татарстан урамы, 90 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Арча муниципаль районы
Наласа авыл җирлеге башлыгы — Шакирова И.Р